ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

№ 79 от 29.10.2024

Татарстан Республикасы Трудолюбово муниципаль берәмлегенен җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча жэмагать тынлаулары уздыруны билгеләү турында

- Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы нигезендә Аксубай муниципаль районы башлыгы Аксубай муниципаль районы Уставы белән карар чыгарды::

- 1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Трудолюбово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча Трудолюбово авыл җирлеге халкы катнашында жэмагать тынлаулары билгеләргә.

- 2. Жэмагать тынлауларын оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

- - Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. М. Мингулов;

- - Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И. И. Исләмов;

- - Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р. Р. Сарвартдинова;

- - Аксубай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М. Ә. Габдрахманов;

- - Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Трудолюбово авыл җирлеге башлыгы С.А.Тарасова

- 3.Жэмагать тынлауларын оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

- 4. Жэмагать тынлауларын үткәрү чорын - кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып жэмагать тынлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Жэмагать тынлауларын уздыру срогы бер айдан артмаска тиеш.

- 5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетына иҗтимагый фикер алышулар башлану турында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 маддәсендә каралган хәбәр әзерләргә.

- 6.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.rn) һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (https://aksubayevo.tatarstan.ru/).
- 7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Вакытлыча Аксубай муниципаль районы
башлыгы вазифаларын башкаручы : И.М. Загидуллин